РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Исполнительный комитет**
**Осинниковского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
***Осинниковское авыл жирлеге***
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Молодежная , 9А, пос.Осинники, 422824
тел. (8843) 3-39-29 факс: (8843) 3-39-29
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ИНН/КПП 1622004651/162201001

Молодежная урамы, 9А, п.Осинники, 422824,
тел. (8843) 3-39-29 факс: (8843) 3-39-29
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ИНН/КПП 1622004651/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 27 августа 2018 г. № 6

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 2 маендагы “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 3 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Осинники авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 2 маендагы 3 санлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.4 пунктына 8, 9 пунктчасыларын өстәргә:

“8) муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт курсәтүен туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.”.

1.2. 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 1-3 абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.12. Шикаять карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул итеинә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шулай ук кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт курсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларга кертелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан республикасы норматив-хокукый актлары, муниципаль норматив-хокукый актлар белән каралмаган түләүләрне кире кайтару формаларында;

2) шикаять канәгатьләндерелми.”.

2. Әлеге карарны  мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Осинники авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Х. Сәгъдиев